БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ ҺӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ
ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №37 (7054) | 27 март, 1990 ел. СИШӘМБЕ | Бәясе 3 тиен.



Раиса Максимовна Тютина «Правда» колхозында инде иң тәҗрибәле савучыларның берседер, мөгаен. Тырыш һәм булдыклы савучы Р. И. Ивотов җитәкчелегендәге подряд звеносында да ышанычлы эшчеләрдән санала. Звено быелның февралендә һәр сыердан 210 килограмм сөт савып алды, хәзер дә савымны арттыра баралар терлекчеләр.

Тагы бер куанычы бар Раиса Максимовнаның: ул —5 бала анасы. Аларны тәртипле һәм хезмәт сөючән итеп тәрбияләүне үзенең зур һәм сөенечле бурычы итеп саный ул.

Рәсемдә: «Правда» колхозы сыер савучысы Р. М. Тютина.

## Яңа колхоз— „Чирмешән"

22 мартта Муса Җәлил исемендәге колхозның Кәкре Атау бригадасы базасында яңа колхоз оештыруга багышланган җыелыш булды. Яңа хуҗалыкка «Чирмешән» исеме бирелде һәм аның председателе итеп бригада агрономы булып эшләгән Җәмил Хәмзиевич Рәхимов сайланды.

Җыелышта КПСС райкомының икенче секретаре Ә. В. Мөлеков катнашты.

### Җәмил Хәмзиевич Рәхимов

Җ. Х. Рәхимов 1957 нче елда Октябрь районының Кәкре Атау авылында туган. Милләте буенча татар. 1989 елдан КПСС члены.

Җ. Х. Рәхимов хезмәт юлын 1974 елда Муса Җәлил исемендәге колхозда механизатор булып башлый. 1979 елда, Лаеш авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлаганнан соң, туган колхозында комсомол оешмасы секретаре булып эшли, аннан, 1981 елда бригадирның техника буенча ярдәмчесе итеп күчерелә. Читтән торып Ульяновск авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый. 1989 елдан бүгенгәчә бригада агрономы була.

## 1990 елның 17 мартында кабат тавыш бирүдә РСФСР халык депутатларын сайлау нәтиҗәләре турында БЕЛДЕРҮ

**868 НЧЕ ЧИРМЕШӘН ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ ОКРУГЫ**

РСФСР халык депутатын сайлау өчен сайлаучылар исемлегенә 110473 кеше кертелгән иде. Тавыш бирүдә 90439 кеше, яки 81,9 проценты катнашты.

1581 сайлау бюллетене дөрес түгел дип табылды.

«РСФСР халык депутатларын сайлау турында» РСФСР Законының 52 нче статьясы нигезендә 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутаты итеп Елена Александровна ШӘРИФУЛЛИНА сайланды. 1953 елда туган. Лениногорск район үзәк больницасының бар врачының балаларны дәвалау буенча урынбасары. Дәвалаучы врач, КПСС әгъзасы, Лениногорск шәһәрендә яши (54,9 процент).

**127 НЧЕ ЛЕНИНОГОРСК МИЛЛИ-ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ ОКРУГЫ**

РСФСР халык депутатын сайлау өчен сайлаучылар исемлегенә 613305 кеше кертелгән иде. Тавыш бирүдә 491543 кеше, яки 80,1 проценты катнашты.

7620 сайлау бюллетене дөрес түгел дип табылды.

«РСФСР халык депутатларын сайлау турында» РСФСР Законының 52 статьясы нигезендә 127 нче Лениногорск милли-территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутаты итеп Ринат Сафа улы МӨХӘММӘДИЕВ сайланды. 1948 елда туган, Татарстан АССР Язучылар союзы идарәсе рәисе, КПСС әгъзасы, Казан шәһәрендә яши (63,5 процент).

**Округ сайлау комиссияләре.**

## Татарстан АССР халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясе БЕЛДЕРҮЕ

1990 елның 17 мартында Татарстан АССРның «Татарстан АССР халык депутатларын сайлаулар турында»гы Законының 52 нче статьясына туры китереп, Татарстан АССР халык депутатларын сайлау буенча 114 сайлау округында кабат тавыш бирү үткәрелде. Шуларның 112 сендә сайлау булды, 9 нчы Университет сайлау округында, Казан шәһәренең Вахитов районы һәм 57 нче Мәүлетов сайлау округында (Казан шәһәренең Идел буе районы) сайлау булмады, чөнки аларда сайлаучылар исемлегенә кертелгән сайлаучыларның яртысыннан кимрәге катнашты.

Кабат тавыш бирү булган сайлау округларында сайлаучылар исемлекләренә 1120184 кеше кертелгән иде. Тавыш бирүдә 742543 сайлаучы, ягъни 66,28 проценты катнашты. 14672 сайлау бюллетене дөрес түгел дип табылды. 1990 елның 17 мартында Татарстан АССР халык депутатлары итеп түбәндәге иптәшләр сайланды:

**226 нчы Завод сайлау округы**

ГАЗИЗУЛЛИНА Любовь Никифоровна —Норлат тимер юл станциясе начальнигы. КПСС әгъзасы, Октябрь районының Норлат шәһәре.

**227 нче Октябрь сайлау округы**

ЕЖОВ Анатолий Николаевич —«Татнефть» производство берләшмәсенең Норлат разведка бораулавы идарәсе шоферы, партиясез, Октябрь районының Норлат шәһәре.

1990 елның 4 һәм 17 мартында 250 халык депутатының 214 е сайланды.

Татарстан АССРның «Татарстан АССР халык депутатларын сайлаулар турында»гы Законының 53 нче статьясына туры китереп, Үзәк сайлау комиссиясе округ сайлау комиссияләренә 1990 елның 22 апрелендә кабат сайлау үткәрергә кушты. 36 сайлау округында кабат сайлау үткәреләчәк.

**Татарстан АССР халык депутатларын сайлау буенча Үзәк сайлау комиссиясе.**

## Сез гә мандат—ышаныч

РСФСР һәм ТАССРга депутатлыкка кандидатларга тавыш бирүнең икенче туры узды. Без 226 нчы номерлы Завод һәм 227 нче номерлы Октябрь сайлау округларыннан Татарстан АССРга халык депутатларына кандидатлар Л. Н. Газизуллина һәм А. Н. Ежов иптәшләрнең кискен сайлау алды көрәшендә ышаныч мандаты яулавын зур канәгатьлек белән кабул иттек.

Хөрмәтле Любовь Никифоровна һәм Анатолий Николаевич, сезне Татарстан АССР халык депутатлары итеп сайлануыгыз белән котлыйбыз. Сайлауларда җиңү сезгә көч, энергия өстәсен, халык алдында иртәгәге көнебез, иҗтимагый тормышның барлык сферасында үзгәртеп коруларның уңышы өчен җаваплылыгыгызны арттырсын.

Үз сайлаучыларыгызның мәнфәгатьләрен яклауда, хезмәттә кыю һәм максатчан булыгыз!

«ДУСЛЫК» ГАЗЕТАСЫ РЕДАКЦИЯСЕ КОЛЛЕКТИВЫ.

## Хезмәт календаренда— апрель

**Октябрьнең 50 еллыгы исемендәге Н. Октябрь шәһәр типографиясе.**

Бу көннәрдә коллективның кәефе күтәренке, күңеле көр. Шулай булмый ни: полиграфистлар товар продукциясе җитештерү буенча беренче квартал планын 24 мартка үтәп чыктылар. Бүгеннән аларның хезмәт календаренда —апрель.

Хәер, коллективның бер төркем уңганнары апрельгә исәпне аннан да иртәрәк ачып өлгерделәр инде. Кулдан хәреф җыючы Римма Ганиева квартал планын 153 процентка үтәде. Римма Зиятдиновна — соңгы елларда коллективта социалистик ярышта әйдәп баручылардан. Рәсеме — районның Мактау китабында. Аның хезмәт уңышлары күп тапкырлар Мактау грамоталары, «Социалистик ярышта җиңүче» билгеләре һәм премияләр белән билгеләнеп килә.

Төпләүче Надежда Григорьевна Моисеева турында да бик күп мактау сүзләре әйтергә мөмкин. Аның эшендә иң кирәкле сыйфатлар — өлгерлек һәм пөхтәлек аңа квартал планын 146 процентка үтәргә мөмкинлек бирде.

Гомумән, коллектив булдыклы эшчеләре белән дан тота. Ә күптән түгел полиграфистлар янә бер уңганнарын зурладылар. Басучы Надежда Степановна Порфирьева өчен генә түгел, тулы коллектив өчен бәйрәм булды ул. Чөнки тугры сүзле, гадел эшче, яшьләр остазы Надежда Порфирьевага 50 яшь тулды. Шул ук датага янә бер шатлык туры килде: ул «Профессиясе буенча иң яхшы» билгесе белән бүләкләнде.

**Л. УХВАНОВА,**
типография бухгалтеры.

Рәсми хроника

## Секретарь сайланды

«Россия» колхозының Каравыл Тавы бригадасы базасында А. И. Кузнецов исемендәге мөстәкыйль хуҗалык оештырылу сәбәпле, КПСС райкомы бюросы карары нигезендә, башлангыч партия оешмасы да төзелде. Колхоз коммунистларының оештыру җыелышында башлангыч партия оешмасы секретаре итеп Т. П. Жирнова сайланды.

### Т. П. ЖИРНОВА

Тамара Павловна Жирнова 1947 елда Октябрь районының Иске Иглай авылында туган. 1973 елдан КПСС члены. Милләте буенча чуваш.

Т. П. Жирнова хезмәт юлын 1965 елда «Звезда» колхозында (хәзерге «Рассвет» совхозы) кош караучы булып башлый. 1967—1970 елларда Минзәлә совхоз-техникумында укый. Аны тәмамлап кайткач 6 ел буена «Россия» колхозында зоотехник-селекционер булып эшли. 1976 елда халык депутатларының Егоркино авыл Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлана һәм 11 ел дәвамында шушы вазифаны башкара. 1987 елдан Каравыл Тавы сигезьеллык мәктәбендә укытучы булып эшли. Быелның гыйнварында исә «Россия» колхозы коммунистлары аны хуҗалыкның партия комитеты секретаре итеп сайладылар.

# Кибетчеләребез әйбәт

Кич булып килүгә дә карамастан, нефтьчеләр микрорайонының «Җиләк-җимеш һәм яшелчә» кибетендә сәүдә кызу бара иде. Бүген ни өчендер сөт продуктларын соң китергәннәр һәм кибетчеләргә җитез булырга туры килде. Эш белән мавыгып, алар хезмәт көне тәмамланганын сизми дә калдылар. Кибеттәге бар халыкны канәгатьләндермичә эш урыннарыннан кузгалмадылар. Өйләренә арып, әмма шат күңел белән кайттылар. Чөнки халык алар эшеннән канәгать иде бит.

Озак еллар буена бу кибеттә Зинаида Степановна Сафина һәм Роза Гобәйдуллина бергә эшлиләр. Икесе дә яшь, икесе дә энергияле. Кешеләрне мөмкин кадәр яхшырак канәгатьләндерү өчен бар көчләрен биреп тырышалар. Кибет киштәләрендә товар ассортименты бай булсын өчен, базага да үзләре юл белә, товарларны да үзләре ташыйлар. Әлеге кибеттән барлык төр авыл хуҗалыгы продуктларын да сатып алырга мөмкин. Кәбестә, кишер, чөгендер, бәрәңге, суган өзелеп тормый.

Шуны да әйтергә кирәк: кибет эче чиста, пөхтә итеп җыештырылган. Барлык товарлар да үз урынында, бәясе язып эленгән. Бирегә керүчеләргә сатучыларга мөрәҗәгать итәргә дә калмый, барысы да күз алдында. Кибетнең чисталыгына җыештыручы Сания Усманова җаваплы. Ул биредә күптән түгел генә эшләсә дә, үзен уңай яктан танытып өлгерде.

Апрель аеннан коллектив (бу вакытта анда тагын бер сатучы Гөлнара Гарифуллина өстәлде) аренда подрядына күчте һәм бу аларга эшкә иҗади килергә мөмкинлек бирде. Һәм менә шунда да инде нәтиҗә. Коллектив товар әйләнеше планын узган елда арттырып үтәде.

Кибеттә сөт һәм икмәк продуктларын күптән түгел генә сата башладылар. Чөнки элеккеге «Икмәк—сөт» кибете кысан иде. Билгеле, сатучыларга мәшәкате артты. Биредә товарларны бушатучы да алар үзләре бит. Шулай да сатучылар кыенлыклар алдында каушап калмадылар, бар эшне дә төгәл һәм зур җаваплылык тоеп башкаралар.

Кызларга карап торасың-торасың да гаҗәпләнеп куясың: алар нинди җитез эшлиләр! Һәркемне көләч елмаеп каршылыйлар, тупас сүз ишетмәссең алардан. Шундый сатучылар күбрәк булсын иде кибетләрдә дип чыгасың биредән.

**Ф. МОСТАФИНА.**



**МӘСКӘҮ.** Танылган модельер В. Зайцев җитәкчелегендәге коллектив эшләгән яңа милиция формасы Мәскәү шәһәр башкарма комитеты эчке эшләр бүлеге Баш идарәсе хезмәткәрләренә тәкъдим ителде.

Бу форма уңайлы булуы белән генә отмый: аның газ йөртү өчен баллончыгы һәм, барлык илләрдәге полицияләрнеке кебек, богаулары да бар.

Мәскәү һәм өлкә милициясе бу формага 1992 елда, ә калганнар 1994 елда күчәчәкләр.

Рәсемдә: аерым назначениедәге милиция отряды һәм ГАИның яңа җәйге формасы.

**БАСЫЛГАНГА КИРЕ КАЙТЫП**

# «Гаражмы, әллә газонмы?»

«Дуслык» газетасының 1990 елның 24 март санында әнә шул баш астында чыккан мәкаләдә халык депутатларының шәһәр Советы башкарма комитеты карары белән чәчәк түтәлләре урынына шәхси гаражлар төзүгә рөхсәт бирелүе турында язылган иде.

Редакция бу турыда ачыктан-ачык сөйләшү көткән иде. Ләкин кызыксынучылар булмады. Хәер, кабат-кабат исләренә төшергәннән соң шәһәрнең ике службасы редакциягә астан-өстән язылган хәбәр җибәрде.

Газ службасы начальнигы Г. Н. Бикинеев җавабында конкрет карарларга катылмыйча, саннарга гына сугылган. Мәкалә авторы аның белән киңәшкәндә ул конкретрак, катгыйрак фикерләр әйткән һәм:

—Биредә бернинди төзелеш булырга тиеш түгел, әле сквер да ярамый, тик чәчәк түтәлләре генә ясарга була. Чөнки кеше газ үткәргеч янында булырга тиеш түгел,—дигән иде.

Ә архитектура бүлеге җавабы бөтенләй шаккаттырды. Без шәһәр ургасында шәхси гаражлар төзүгә карата компетентлы фикер көткән, нәкъ менә белгечтән шәһәребезнең йөзен гаражлар белән түгел, чәчәк түтәлләре ясап бизәү турында сүз ишетергә теләгән идек.

Тагын бер фактка тукталып үтми мөмкин түгел. Район архитекторы редакциядән хат алгач, үз фикерен юклыктандыр инде, район хәрби комиссариатына киңәшкә ашыккан.

Гафу итегез, бу җавап түгел (әле җавапдагы беренче имза да хәрби комиссариатныкы).

Беренчедән, җавапта: «Район хәрби комиссарлары составы күрсәтелгән урында шәхси гараж салырга уйламый»,—диелгән.

Моннан шулай килеп чыга, шәһәр Советы башкарма комитеты председателе иптәш Фәррахов авторга бу фактны хәбәр итеп шаярткан булып чыга. Ә бит автор шәһәр Советы тиң бер генә карар кабул итүен яшерми. Нәкъ менә шушы факт шиккә төшерде дә.

Мәкаләне язганда авторның хәрби комиссариатка да, ветераннар советына да гаражның булачак хуҗалары исемлеген төгәл белер өчен мөрәҗәгать итмәүләре турындагы гаепләү кискен яңгырый.

Чынында исә, хәрби комиссариат И. М. Бавин: «бу телефоннан сөйләшә торган сүз түгел», дип исемлекне күрсәтергә теләмәде, ә корреспондент белән очрашуны бернинди сәбәпсез суза килде.

Ветераннар советы председателе иптәш Петров бу көнне чирләп киткән иде һәм автор аның белән телефоннан сөйләште. Һәм ул өч фамилия — Петров, Сергеев, Бавин фамилияләрен атап серне бераз ачты. Ә калган булачак гараж хуҗалары исемен Бавиннан белергә кирәк иде.

Моннан нәрсә килеп чыга, ветераннар гаражга урын сорыйлар, ә аңа мохтаҗлар үзләре юк.

—Гаражлар шәһәрнең йөзен бизәрме?—дигән сорауга архитектор Батыршина:

—Билгеле, юк. Шәһәр йөзен бозучы объектлар аз мыни алар: ит комбинаты, УТТ промбазасы, чистарту корылмалары һәм башкалар,—дип тезеп китте.

Чыннан да, шәһәрнең чәчәк үстерәсе урынннарында чүп-чар, кирәксез объектлар күп әле. Ләкин боларга яңаларын өстәү безгә мораль хокук бирәме соң? Менә бит сорау нидә.

Шәһәр Советыннан һәм халык депутатларыннан җавап юклыгы кызганыч. Бәлки алар элеккеге вакыттагы кебек шулай дәшми калырбыз, үтәр китәр дип уйлыйлардыр.

**Г. ХӘЛИУЛЛИНА.**

**• ЯҢА ЙОЛАЛАРГА—КИҢ ЮЛ!**

# Котлы булсын туегыз!

Туй күлмәге кигән кыздан,
Көнләшеп тә үләрлек,
Туй күлмәге бер көнлекме,
Туй күлмәге гомерлек.

7 март көнне шундый бәйрәмгә яңа өйләнешүче парларны котларга культура йортына бөтен авыл җыелды. Яшь парлар: Фәнүзә һәм Зиннур Асылмәрдәновлар, Миннегөл һәм Талип Мусиннар, Гүзәлия һәм Минзаһир Әхмәтсафиннар, Фәһимә һәм Минислам Мөхәммәтовлар һәм иң яшь парлар Илдар һәм Минсәрия Мостафиннар. Кызлар ап-ак туй күлмәкләреннән. Бүген иң шатлыклы, иң истәлекле көннәре аларның.

Әйе, туй күлмәге сезнең өчен мәңгелек булсын, гомерегезнең соңгы көненә чаклы кулга-кул тотынып, бер-берегезнең кадерен белеп гел бергә булыгыз! Ак юл сезгә, яшь парлар!

Яшь парларны котлап җырлар җырланды, матур теләкләр әйтелде. Берләшмә директоры Н. М. Шәйхиев яшь парларга акчалата ярдәм—кыйммәтле бүләк, ә бергә эшләүче иптәшләре истәлек бүләкләре тапшырдылар.

Бу кичәдә хәрби хезмәттән кайткан, туган авылында эшкә калырга теләк белдергән Илһам Хәйретдинов та бар иде. Ул берләшмәдә зоотехник булып эшли һәм Буа совхоз-техникумында читтән торып укый. Илһамга да теләкләрнең матурлары әйтелде, кыйммәтле бүләкләр бирделәр. Илһам да җавапсыз калмады: ышанычларын акларга дип авылдашларына сүз бирде.

Кичәнең тантаналы өлешеннән соң авылыбыз үзешчәннәре концерт күрсәттеләр: җырлар җырланды, өздереп биеделәр.

Кыскасы, бәйрәм кичәсе барысына да ошады.

**М. САБИРОВА.**
Югары Норлат авылы.

## БЕЛДЕРҮЛӘР

«Татавтотранс»ның (автомәктәп) Лениногорск уку комбинаты 17,5 һәм өлкәнрәк яшьтәге егетләрне укырга чакыра. Ул предприятие, совхоз, колхозлардан направление белән алар исәбенә производстводан аерылып «В» һәм «С» категорияле шоферларны хәзерли. Уку бөтен төр автомобильләрдә алып барыла. Уку срогы 5 ай. Читтән килүчеләргә тулай торак бирелә. Уку 1990 елның 2 апрелендә башлана.

Адресы: Лениногорск шәһәре, Асфальтная урамы, 2.

Телефон: 2—0—69.

x x x

«Ульяновсктрансстрой» трестының 634 нче төзү-монтаж поездына даими эшкә хезмәтне оештыру һәм нормалау буенча инженер-мастер, ПТО начальнигы кирәк. Түләү штаттагы расписание буенча һәм 15 процент район коэффициенты өстәлә. Читтән килүчеләргә 5 ел дәвамында 30 процент өстәмә түләү. Шулай ук тимер юл транспортында эшләүчеләр өчен каралган льготалардан файдаланалар (бәясе 50 процент скидка белән күмер һәм бер елга бер тапкыр түләүсез билет бирелә).

Ялгызакларга тулай торак бирелә.

Адрес: Норлат шәһәре, Молодежная урамы, 1 нче йорт.

Телефон: 2—21—50. Тимер юл коммутаторы аша 1—71.

x x x

1990 елның 15 мартыннан алып 15 майга кадәр универмаг бухгалтериясендәге Норлат шәһәре райпо пайчыларын теркәү бара. Аны үтмәгән пайчылар райпо Уставы белән каралган льготалардан мәхрүм ителәләр.

Шул ук вакытта Октябрь райпо идарәсе түбәндәгеләрне хәбәр итә: райпо пайчылары үзләренең ирекле акча средстволарын райпоның финанс-хуҗалык эшчәнлегенә кертә алалар. Акча средстволарыннан файдаланган өчен райпо аларга 4 процент еллык өстәмә түли, ә 3 меңнән артык акча кертүче пайчыларга кертелгән пайның 20 процентына иң кирәкле товарлар алу мөмкинлеге тудырыла (товар ресурсларыннан чыгып). Бу мәсьәлә буенча райпо бухгалтериясенә мөрәҗәгать итәргә. Телефон: 2—14—65.

РАЙПО ИДАРӘСЕ.

РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: редактор—2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь—2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары—2—15—63, агропромышленность бүлеге—2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды.
Асия Моратханова верстка ясады.
Клара Бобкова басты.
Корректор—Зөлфия Вәлиева.

Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 37. Тираж 3.877.